ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

Урта Юрткүл авыл җирлегенең Фадеевка торак пунктында

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының

2024 елның 13 ноябрендәге 4-2 номерлы

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Урта Юрткүл авыл җирлегенең Фадеевка торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

Карар кылдым:

1.2025 елда Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Урта Йрткүл авыл җирлегенең Фадеевка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Фадеевка торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны (энергияне саклый торган яктырткычлар һәм урамнарны яктырту лампаларын сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү) ремонтлау;

2) Фадеевка торак пункты территориясен төзекләндерү (МТЗ-82 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү (карны чистарту));

3) су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Фадеевка торак пунктында сусүткәргеч челтәрләрен ремонтлау (килешү буенча эшләр өчен түләү)».

3. Әлеге карарны Урта Йорткүл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерергә, Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http:// spasskiy.tatarstan.ru). хокукый мәгълүматның рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru//в кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында бастырып чыгарырга .

Гражданнар җыенында рәислек итүче,

Урта Йорткүл авыл җирлеге башлыгы

Спас муниципаль районының А. В. Веселова

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «СРЕДНЕЮРТКУЛЬСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ СРЕДНЕЮРТКУЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ